СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №130 (7459) | 31 октябрь, 1992 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

ДУСЛЫК

**Хөрмәтле укучылар!**

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**

## Тагын приватизация чеклары турында

**Ноябрь ае алдыннан халык арасында әлеге темага сөйләшү, сораулар тагы да кызыксынучанрак төс алды. Әңгәмәдәшебез — коммуналь мөлкәт белән идарә итү комитеты рәисе, район администрациясе башлыгы урынбасары Р.Р. ЙОСЫПОВ ваучерларны алу тәртибе турында түбәндәгеләрне сөйләде:**

— Татарстан Республикасы Президентының Татарстан гражданнарына дәүләт мөлкәтен тапшыру, приватизация процессына киң катлам халыкны тарту һәм Россия Федерациясенең бердәм экономик киңлеген саклау максатында игълан иткән мәгълүм Указы нигезендә, Татарстан территориясендә 1992 елгы номиналь бәясе 10 мең сумлык Россия Федерациясе чекларын бирә башлау 1 ноябрьдән дә соңга калмыйча башкарылырга тиеш иде. Алар авыл Советлары, торак-коммуналь идарәләр (ЖКХ), күптармаклы производство предприятиесе (МПП), торак фонды булган предприятие һәм оешмалар тарафыннан төзелгән исемлек нигезендә саклык банкы һәм аның филиаллары аркылы бирелә. Аны таратуда тәртип булдыру максатында, территориаль комиссия тарафыннан торак пунктларны, МПП, ЖКХ, ЖКО, торак фонды булган оешма-предприятиеләрне саклык банкына һәм аның филиалларына беркетү үткәрелде.

Түбәндә без газета укучыларга әлеге схеманы тәкъдим итәбез. Аннан чыгып, кеше ваучерларны алу өчен кая килергә икәнлеген тиз аңлар. Әйтик, граждан яшәгән йорт шикәр заводы ЖКОсына карый, димәк, ул приватизация чегын алу өчен саклык банкының шикәр заводы микрорайонындагы филиалына барырга тиеш. Инде тимер юл районында индивидуаль секторда яшәүче кеше тимер юлчылар клубына мөрәҗәгать итә. Шуңа игътибар итегез: схемада гы күрсәтелгән оешма-предприятиеләр анда эшләүчеләрне түгел, аларга карый торган торак фондта яшәүчеләрне күздә тота, чөнки исемлекләр гражданнарның тору урыны буенча төзелгән. Приватизацион чеклар белән бергә гражданнарга алардан файдалану тәртибен аңлаткан памятка да биреләчәк. Шунысын да онытмагыз: чек тапшырылганда, аңа 25 сум күләмендә комиссион салым түләргә туры киләчәк.

Инде соңгысы: Россия Федерациясенең бу приватизацион чеклары безнең республикада 1993 елның 1 январеннан 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак. Шуңа да гражданнардан бу эшне тынычлык, сабырлык белән, кабаланмыйча гына башкаруларын сорыйбыз. Шулай итеп, 2 нче ноябрьдән саклык банкы һәм аның филиаллары сезнең өчен чеклар бирүне башлап җибәрә.

Гражданнарның паспортларын һәм балаларының туу турындагы таныклыкларын алып килүләре сорала.

## Торак пунктларны, МПП, ЖКХ, ЖКО, торак фонды булган оешма-предприятиеләрне саклык банкының Н.-Октябрь бүлеге һәм аның филиалларына беркетү

| Банк филиалы номеры һәм урнашкан урыны | Торак пункт, МПП, ЖКХ, ЖКО, торак фонды булган оешма-предприятиеләр исемнәре |
|---|---|
| 023 нче шикәр заводы филиалы | Шикәр заводы ЖКОсы, хуҗалыкара төзелеш оешмасы ЖКХсы, икмәк заводы, азык комбинаты, орлыкчылык станциясе; шикәр заводы поселогында Маяковский, Московская, Циолковский, Тукай, Ленин урамнарында шәхси секторда яшәүчеләр, Югары Норлат авылы. |
| Тимер юлчылар клубы | 30 нчы йортлар идарәсе, НУГР РСУсы (634 нче СМП), «Агропромхимия», «Коопзаготпром»; тимер юлчылар поселогында Садовая, Толстой, Овражная, Фрунзе, Горький урамы һәм тыкрыгы, Комсомольская, Линейная, Куйбышев, Островский урамы һәм тыкрыгы, Красноармейская, Ватутин, «40 лет Октября», Пионерская, Лобачевский, Декабристлар, Бауман, Лермонтов урамы һәм тыкрыгы, Чернышевский, Восточная, Гончаров, Кутузов, Суворов, Гоголь, Энгельс, Димитров, Калинин, Киров, Западная, Полевая, Спартак, Первомайская, Кузнецов, Южная урамы һәм тыкрыгы, Красин урамнарында шәхси секторда яшәүчеләр, Түбән Норлат авылы. |
| 037 нче Нефтьчеләр микрорайоны | «Норлатнефть» НГДУсы ЖКХсы, НУГР, НУЭООС, 2 нче СМО, «ТатАИСнефть», 53 нче СМУ, ремтехпредприятие, «Агропроммехмонтаж» ПМКсы; Победа, Дружба, Космонавтлар, Мир, Киевская, Северная, Шашин, 60 лет Октября, Промышленная урамнарында шәхси секторда яшәүчеләр, Чишмә, Кормыш, Чуваш Мәнҗесе, Тарн-Вар, Пушкин авыллары. |
| 4676 нчы саклык банкының үзәк бүлекчәсе | Көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе, «Фармация» производство предприятиесе, ветстанция, җылылык челтәре, машзавод, «Татжилгражданстрой» РСУсы, тара ремонтлау участогы, зооветснаб, сәүдә базасы, урман склады, райпо, райфо, элемтә узелы, УРСЖ, ит комбинаты, ДРСУ, АТП, элеватор, подстанция, үзәк район больницасы, «Тасфир» филиалы (госстрах), нефть базасы, 127 нче ПМК, магистраль газүткәргеч идарәсе, сөт-май комбинаты, МПП, райпо АТХсы, 99 нчы СПТУ; Советская, Октябрьская, Муса Җәлил, Ленинградская, Ломоносов, Чапаев, Мичурин, Чкалов, Лихачев, Школьная урамы һәм тыкрыгы, Степан Разин, Нариманов, электростанция, Синдряков, Тельман урамы һәм тыкрыгы, Спортивная, Карл Маркс, Пушкин урамнарында шәхси секторда яшәүчеләр. |

### Графикны узып

Ятмаларны эшкәртү башланганнан бирле Татарстан нефтьчеләре җир астыннан 2,5 миллиард тонна «кара алтын» чыгардылар. Аларга хәзер базар экономикасына күчүнең кыен шартларында, хуҗалык элемтәләренең ныклы булмавын адым саен тоеп эшләргә туры килә. Шуңа да карамастан, «Татнефть» берләшмәсенең нефть чыгаручылары быел 29,6 миллион тонна нефть алырга сүз бирделәр, аның 800 мең тоннасы дәүләт заказыннан тыш алынырга тиеш.

### ЯҢА КИБЕТ АЧЫЛДЫ

Урман эчендә урнашкан Кызыл Юл поселогында ике кибет тә кысан, иске биналарга урнашкан, сәүдә итү, товар һәм продуктларны саклау өчен нормаль шартлар юк иде.

Ниһаять, байтак елларга сузылган сорау, үтенечләрдән соң, биредә таш кибет өлгерде. Типовой проект белән салынган бу катнаш кибет Октябрь урман пункты эшчеләренә сәүдә хезмәте күрсәтүне күпкә яхшырта.



«Төрнәс» совхозының товарлыклы-дуңгызчылык фермасында Ольга Викторовна Камалова озак еллар хезмәт куя. Бүгенге көндә ул 2 айга кадәр һәм аннан да зуррак булган дуңгызлар карый. Агымдагы елның 9 аенда алардан әйбәт артым алуга иреште. Аның хезмәттәше Әлфия Хәмәтсәлиховна Кәлимуллина турында да шундыйлы сүзләр генә әйтергә була. Яшь дуңгызлардан яхшы үсеш алу өчен Әлфия Хәмәтсәлиховна да зур тырышлык куя.

РӘСЕМДӘ: О. В. Камалова һәм Ә. Х. Кәлимуллина.

# Кич утырганда

Өлкән авторыбыз МӨНӘВӘРӘ УСМАНОВА.

## АК ӘБИ

Мәрьям әби керләр юып әлгән,
Ялгыз йортка шуңа ямь кергән,
Морҗасыннан сызыла зәңгәр төтен,
Тәрәзенә гөлләр үрелгән.

Ире һәлак булгач авыр чорның
Саллы йөген салып җилкәгә,
Сыкранмыйча узды гомер юлын
Яше сиксән бишкә җитсә дә.

Җилбер-җилбер искән җилләр белән
Җилфердиләр ап-ак керләре.
Кая калды икән киң кырларда
Җилтер-җилтер эшләп йөргәне.

Сәҗдәсендә җанын тәслим кылган,
Ә учакта көйри күмере,
Самовары гөжләп кайнап тора,
Тик өзелгән фани гомере.

Берәүгә дә гозер, борчу салмый
Сабыр гына китте изге җан.
Иман нуры иңгән Ак Әбине
Мәңгелеккә җуйды бу җиһан.

«Хилафлык килмәсен намазыңа!»
Ак керләрен юган бик пакълап,
Һичбер таптыз, ак һәм пакъ керләре
Гомер юлын тора раслап.

## „Канатлы ат“ китабың калган өстәлеңдә

**Фаҗигале төстә һәлак булган оныгым Илдарга багышлыйм.**

Чиксезлектә җир—бер нокта гына,
Мәңгелектә гомер—бер мизгел,
Гадигә дә, бөек даһига да
Үлем генә килә бер тигез.

«Канатлы ат» калган өстәлеңдә,
Җайдагы юк нигә иярдә?
Ах, син үлем! Уйнап туймас җанга
Нигә кирәк иде тияргә..

Киң болыннар буйлап
«Яшь тай» булып уйнап
Офыкларга иде җитәсе,
Канатлы атларда дөнья буйлап
Гизәсе дә иде, гизәсе...

Офыкларны әллә тарсынышмы
Мәңгелеккә күчте саф җаның,
Белми идең әле... Чирмешәннең
Чоңгыллары бөтереп алганын.

Чагылып кына уздың яшәештән,
Калганнарга сагыш-моң булып,
Һәр таң саен кайтасың син миңа
Чиксезлектән якты нур булып.

Чит өлкәдә яшәүче якташыбыз иҗаты.
Гакыйль СӘГЫЙРОВ

## АДӘМ БАЛАСЫ

Яши җирдә—якын дуслары күп,
Дошманы күп, үтәр юллары.
Күпне күргән саен яшькә йомшый
Һәм нечкәрә күңел кыллары.

Яши җирдә. Ул ашкынып атлый.
Ымсындыргыч якты таңнарга.
Офык ерак, җитәрменме?—дими,
Капланмаммы дими ташларга?

Ул—гөнаһлы, сәер, ул саваплы,
Ул—җаваплы күпләр каршында,
Дөнья гизә мәңге килгән сыман
Һәм калдырып китә барсын да..

## Яфракларын коя өрәңге

Яфракларын коя өрәңге...
Күрше сабыйларын сөя-сөя
Тол хатыннар казый бәрәңге.

Алырлармы көзләр җиткәнче?—
Казып китсә—юктыр чүпләүче...

Һәр көн иртән ялгыз—бакчада,
Ярдәм диеп керми, зарланмый.
Әйтерсең лә күптән бомбалар
Күмгән бәхетен эзли—табалмый...

...Яфракларын коя өрәңге.
Кара җиргә каргыш күмә-күмә,
Тол хатыннар казый бәрәңге..



**Ислам дине гомер-гомергә халыкны әдәплелеккә, инсафлыкка өндәгән, мөселманнарны тәртипкә чакырган. Демократия тамыр җәя башлагач, ислам кануннары тормышта киң яшәеш таптылар. Яңадан-яңа мәчетләр калкып чыга, авыллар өстендә күңелләргә иман нуры иңдереп моңлы азан тавышлары яңгырый.**

**Шунысы характерлы, хәзер инде мәчеткә намазга картлар гына түгел, хатын-кызлар, яшьләр дә йөри.**

**Рәсемдә: намаз вакытында.**



**Милли кием ничек килешә үзенә (шәһәрнең 2 нче балалар бакчасында бәйрәм).**

## *Менә шундый заман җитәр*

**МӨНӘҖӘТ**

Дөньяда иман бетәр, халык карар уңга-сулга,
Изге гамәл һич кылмаслар маллары күп булганга.
Ата-анада хәят бетәр, балаларда шәфкать бетәр,
Туганнардан рәхим бетәр, менә шундый заман җитәр.
Биналары биек, күп булыр, эче тулы зиннәт булыр,
Дөньясы бозык булыр, менә шундый заман җитәр.
Зур-зур биналар салырлар, ашыгып аңа барырлар,
Эчеп гауга кубарырлар, менә шундый заман җитәр.
Яшәүләре нәүбәт белән, хезмәтләре сәгать белән,
Ризыклары үлчәү белән, менә шундый заман җитәр.
Яхшыларга юл ачмаслар, яманнарга сүз катмаслар,
Ахирәт дип һич әйтмәсләр, менә шундый заман җитәр.
Машиналар чабып торыр, кайберләре авып торыр,
Халыклары үлеп торыр, менә шундый заман җитәр.
Ата-ана карап торыр, балалары хөкем итәр,
Ни булганын һичкем белмәс, менә шундый заман җитәр,
Үз туганын танымаслар, хәлен барып сорамаслар,
Чит кешене дус күрерләр, менә шундый заман җитәр.
Җаннары һич тыныч булмас, тәннәрендә сихәт булмас,
Кайда нишләрен белмәс, менә шундый заман җитәр.

**Сөекле әниебезне җирләүдә катнашкан туганнарыбызга, тирә-күршеләребезгә, якыннарыбызга, хезмәттәшләребезгә, хәсрәтебезне уртаклашкан һәркемгә газета аша олы рәхмәтебезне җиткерәбез.**

**ӘНӘС ҺӘМ МӨНИРӘ ХӘСӘНШИННАР.**

**МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.**

**Учредительләр: редакциянең хезмәт коллективы һәм халык депутатларының Октябрь район Советы.**

**Редакциянең адресы: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19. Телефоннар: мөхәррир 2—12—14, 2—22—81; мөхәррир урынбасары һәм советлар тормышы бүлеге 2—10—44; рус теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—14—16; чуваш теленә тәрҗемә итү буенча мөхәррир урынбасары 2—15—63; авыл хуҗалыгы бүлеге 2—10—44; яңалыклар һәм промышленность бүлеге 2—22—51; җаваплы секретарь, хатлар, массалар белән эшләү, радиотапшырулар бүлеге, бухгалтерия һәм реклама бүлеге 2—18—67; фотокорреспондент 2—15—63.**

**Газетаның басылу сыйфаты турында типография директорына түбәндәге телефон белән мөрәҗәгать итәргә: 2.10-54.**

**Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Нина ТОЛМАЧЕВА верстка ясады. Наташа ЛУКОЯНОВА басты. Корректор—Зөлфия ВӘЛИЕВА.**

Күләме—1 басма табак.

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә. Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе. Тираж 3751. Заказ 130.**